ФГБОУ ВО «БГПУ» им. М. Акмуллы
Центр развития одаренности школьников

**ЗАДАНИЕ**
**3 тура дистанционной олимпиады по татарскому языку и литературе**
**для учащихся IX класса**

Язын бөреләнеп яфрак ярырга әзерләнгән агачлар белән әңгәмә корыгыз.

Яз ул һәр елның үзенчә матур, үзенчә гүзәл, искиткеч кабатланмас бер вакыты. Бу вакытта шәһәр һәм авыллар кышкы йокыдан соң җанлана, яңача сулыш ала башлый. Көннәр озыная, кояш көннән-көн яктырак, җылырак, ягымлырак, назлырак, иркәрәк карый. Нәкъ менә яз көне бездә нәрсәдер эшләү, планнар төзү дәрте, нирдидир кеше кулыннан килмәслек, көч җитмәслек әйберләр майтару, башкару (хәтта законсыз эшләр белән шөгыльләнү) кебек теләкләр туа,үз тормышыбызны тулысынча үзгәртәсе килә. Тик кайчагында чынбарлыктан, гади тормыш мәшәкатьләреннән качып китәсе һәм табигать белән аралашасы гына килә. Ничек тә булса аны яхшырак беләсе, аны яхшырак таныйсы иде.  Табигать - ул сер, ул- могҗиза. Сер,  чөнки аны ачып бетереп булмый, могҗиза - аны аңлап бетереп булмый. Ни генә булмасын, табигать барсын да аңлый, уйлый һәм ул үзен төрлечә сиздерә.Чөнки агачлар,куаклар, чәчәкләр дә җанлы. Алар теләсә кайсы вакытта сине тыңлый һәм киңәш бирә ала. Әмма кызганычка каршы, без бик еш кына саңгырау, сукыр, чукрак, телсез җан ияләре кебек гомер итәбез: берни, күрмибез, белмибез, аңламыйбыз. ишетмибез һәм дәшмибез.Бүгенге көндә табигать белән аралашу безгә бик мөһим.Чөнки нәкъ менә табигать - Җир ана - гел безнең белән.

ВЫПОЛНИЛ

Фамилия___Бадамшина______________
Имя________________Алия______________
Отчество________Дагиевна_______________
Класс____________9 ”А”__________________
Школа_____________1________________
Город (село)_____________Дюртюли____________
Район__Республика Башкортостан Дюртюлинский район______________
Ф.И.О. учителя___Галимьянова Руфина Фаритовна______________